КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 февраль г.Казань № 61

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары белән расланган Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 21 октябрь, 788 нче, 2017 ел, 26 гыйнвар, 30 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә, 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы агымдагы финанс елның 30 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектына материаллар составында озак сроклы чорга Татарстан Республикасы Бюджет фаразын (Бюджет фаразы проекты, Бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) җибәрә (Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин